**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7961**
**07.12.2021**

«Ел эшмәкәре» шәһәр
конкурсы үткәрү турында

Эшмәкәрлекне популярлаштыру максатында һәм Башкарма комитетның 2019 елның 30 октябрендәге 5586 номерлы карары белән расланган «2020-2023 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасын үтәү йөзеннән, шәһәр Уставының 53 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенә 2021 елның декабрендә Яр Чаллы шәһәрендә «Ел эшмәкәре» шәһәр конкурсын (алга таба – конкурс) үткәрергә.

2. Расларга:

1) конкурс турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурска әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурска әзерлек һәм аны үткәрү чыгымнарын финанслауны 2021 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 30200,00 (утыз мең ике йөз) сум күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе | Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 7 декабрендәге
7961 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Ел эшмәкәре»
шәһәр конкурсы турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә Яр Чаллы шәһәрендә «Ел эшмәкәре» шәһәр конкурсын (алга таба – конкурс) оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели. Конкурсны оештыручы булып Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе тора.

2. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

Оештыру комитеты түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

1) конкурсны үткәрү тәртибен аңлата;

2) конкурска кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кабул итә;

3) конкурсның эксперт жюри әгъзалары составын формалаштыра;

4) конкурс финалын үткәрү көнен билгели.

2 бүлек. Конкурсның максаты һәм бурычлары

3. Конкурсның максаты булып кече һәм урта бизнесны популярлаштыру, шулай ук уңышлы тәҗрибәне тарату тора.

3. Конкурсның бурычлары:

1) эшмәкәрлек белән шөгыльләнүнең позитив имиджын формалаштыру һәм популярлаштыру;

2) эшмәкәрлек эшчәнлеген алып баручы актив һәм сәләтле кешеләрне ачыклау һәм бүләкләү.

3 бүлек. Конкурсны үткәрү шартлары

5. «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына караган, үз эшчәнлекләрен Яр Чаллы шәһәрендә гамәлгә ашыручы шәхси эшмәкәрләр, гамәгә куючылар, гамәлгә куюда катнашучылар, юридик затларның җитәкчеләре катнаша ала.

6. Кандидатуралар турында мәгълүмат, карап тикшерү өчен, otdelsmp@yandex.ru электрон адресы буенча оештыру комитетына җибәрелә, белешмәләр өчен телефон – 30-56-27. Оештыру комитеты заявкаларны карап тикшерә һәм эксперт жюрига тәкъдим итү өчен кандидатураларны билгели.

7. Конкурста катнашуга түбәндәге компанияләрне тәкъдим итүче затлар кертелми:

1) Россия Федерациясе законнары белән тыелган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы;

2) алкогольле һәм спиртлы продукция, сыра һәм аның нигезендә җитештерелгән эчемлекләр, шулай ук тәмәке, тәмәке эшләнмәләре, тәмәке тарту кирәк-яраклары җитештерү яки сату буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыручы;

3) азартлы уеннар оештыручы һәм үткәрүче.

8. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:
1) Бизнес-шәхес;
2) Социаль җаваплы бизнес;
3) Уникаль продукт;
4) Бизнес-инновация;
5) Бизнес-уңыш;
6) Динамик бизнес;
7) Тотрыклы үсеш;
8) Әни-эшмәкәр;
9) Маркетинг алымы;
10) Бизнес-алга китеш;
11) Ел франшизасы;
12) Бизнес-леди;
13) Ел визионеры.

## 3 бүлек. Конкурска йомгак ясау

9. Барлык номинацияләрдә конкурста катнашучыларны бәяләү өчен гомуми критерийлар түбәндәгеләр:

1) активлык дәрәҗәсе (конференцияләрдә, күргәзмәләрдә, шәһәр чараларында катнашу);

2) медиалылык (массакүләм мәгълүмат чараларындагы басмалар, Интернет челтәрендә предприятие һәм аның эшчәнлеге турында киңәйтелгән мәгълүмат);

3) бизнесның актуальлеге, кирәклеге (кешеләр өчен, төрле тармаклар үсеше өчен зарурлыгы һәм кирәк булуы);

4) халыкның мәшгульлеген оештыру (эш урыннары булдыру, эшкә урнаштыру);

5) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә, эш хакы түләү, Россия Федерациясенең бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле салымнар, җыемнар түләү һәм башка түләүләр, шулай ук мәҗбүри пенсия һәм медицина иминиятенә иминият взнослары буенча бурычлар булмау;

6) эш хакын хезмәткә түләүнең минималь күләменнән кимрәк түләү факты булмау;

7) предприятие үсешенең уңай динамикасы.

10. Конкурста катнашучылар эксперт жюри әгъзалары тарафыннан түбәндәге бәяләү критерийлары нигезендә бәяләнә:

| Т/с | Критерий | Максималь бәя |
|---|---|---|
| 1. | Активлык дәрәҗәсе | 10 |
| 2. | Медиалылык | 10 |
| 3. | Бизнесның актуальлеге, кирәклеге | 15 |
| 4. | Халыкның мәшгульлеген оештыру | 15 |
| 5. | Бурычлар булмау | 15 |
| 6. | Эш хакын хезмәткә түләүнең минималь күләменнән кимрәк түләү факты булмау | 15 |
| 7. | Предприятие үсешенең уңай динамикасы | 20 |
| Максималь йомгаклау бәясе | | 100 |

11. Һәр номинациядә җиңүчеләр иң күп уртача баллга ия катнашучылар арасыннан, эксперт жюри әгъзалары тарафыннан билгеләнә. Уртача балл тиешле заявкага эксперт жюри әгъзалары тарафыннан куелган баллар суммасын әлеге заявканы караучы жюри әгъзалары санына бүлеп исәпләп чыгарыла. Берничә претендентның уртача баллары тигез булган очракта, җиңүчеләрне сайлау жюри әгъзаларының ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавышы нигезендә үткәрелә.

12. Эксперт жюриның эш нәтиҗәләре беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә.

13. Һәр номинациядә берәр җиңүче билгеләнә. Конкурс җиңүчеләре истәлекле сувенирлар белән бүләкләнә.

14. Оештыру комитеты өстәмә махсус призларны гамәлгә кую хокукына ия.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева